## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮРӘЗМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XIII УТЫРЫШЫ

## Карар №22

Үрәзмәт 25 май 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 26 декабрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегенең норматив хокукый актларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль законга, «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында»гы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул итүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Үрәзмәт авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ**:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 26 декабрендәге 1номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 бүлекнең 1 кисәгендәге 3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәгечә бирергә:

«4) хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, хезмәт кенәгәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;»;

2) 8 бүлекнең 1 кисәгендәге 1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәгечә бирергә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу вакытында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм тапшырылган белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль

(персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;»;

3) 4 бүлекнең 1 кисәгендәге 3 пунктның 6 пунктчасын түбәндәгечә бирергә:

«6) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ;»

2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл жирлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 4 июнендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл жирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Үрәзмәт авыл жирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Үрәзмәт авыл жирлеге башлыгы Ә.Г.Закирҗанов